**Шәһәр күләмендә Татарстан һәм татар халкы тарихы фәненнән үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы сораулары 2017-18 уку елы**

**9 нчы сыйныф**

Биремнәрне үтәү өчен 2 сәгать вакыт бирелә.
Иң югары балл – 34 балл.

**1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз. 5 биремгә 1әр балл (иң югары – 5 балл).**

**1. Рәсемдә нинди бина сурәтләнгән?**



А. Татар дәүләт «Әкият» курчак театры
Б. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (“Игенчеләр сарае”)
В. Казан (Идел буе) федераль университеты
Г. В.Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театры
Җавап:________________________________

**2. 1917 елның апрелендә мөселман социалистик комитетының (МСК) башлыгы булып кем билгеләнә?**
А) И.С. Алкин  Б) М.Х. Солтангалиев  В) Г. Исхакый  Г) М. Вахитов

Җавап:______________________________

**3. Казан дәүләт университетының 200 еллыгы кайчан билгеләп үтелә?**
А) 2004 елда;  Б) 2002 елда;  В) 2006 елда.

Җавап:_____________________________

**4. 1920 елның 27 маенда:**

А) Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасына В.И. Ленин ордены бирелә;

Б) ТАССРның эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советларының I оештыру съезды булып уза;

В) ТАССР төзелү турындагы декрет кабул ителә;

Г) ТАССРның вакытлы революцион комитеты (Татревком) оеша.

Җавап:____________________

**5. Беренче тапкыр ТССР Президентын сайлау кайчан була?**

А) 6 ноябрь, 1992 ел Б) 2 гыйнвар, 1991 ел

В) 12 июнь, 1991 ел Г) 6 сентябрь, 1990 ел

Җавап:_____________________

## 2 бүлек. Туры китерүгә нигезләнгән биремнәр

**6. Вакыйганы һәм датаны туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| Вакыйга | Дата |
|---|---|
| 1) Мөселман комитеты төзелү | А) 1906, 22 декабрь |
| 2) Казанда Бөтенроссия мөселманнарының II хәрби корылтае ачылу | Б) 1917, 7 март |
| 3) Казанда татар телендә халыкка беренче тамаша күрсәтелү | В) 1934, 3 гыйнвар |
| 4) СССР ҮБК Президиумының ТАССРны Ленин ордены белән бүләкләү турындагы карары чыгу | Г) 1918, 8 гыйнвар |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**7. Галимнәрне һәм аларның эшчәнлек өлкәләрен туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| Галим | Эшчәнлек өлкәсе |
|---|---|
| 1) Н.Г.Чеботарев | А) химия |
| 2) С.А.Альтшулер | Б) математка |
| 3) Г.Х.Камай | В) астрономия |
| 4) А.Д.Дубяго | Г) физика |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**8. Әдәбият һәм сәнгать әһелләренең исемнәрен аларның иҗат иткән әсәрләре белән туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| Исем | Эшчәнлек өлкәсе |
|---|---|
| 1) Н.Җиһанов | А) “Игеннәр өлгерде” |
| 2) К.Максимов | Б) “Алтын йолдыз” |
| 3) Л.Фәттахов | В) “Шагыйрь” |
| 4) Г.Әпсәләмов | Г) “Наратлык” |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**9. Татар драматургларының исемнәрен аларның әсәрләре белән туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 3 б.)**

| **Драматург** | **Әсәр** |
|---|---|
| 1) К.Тинчурин | А) “Банкрот” |
| 2) Т. Миңнулин | Б) “Сүнгән йолдызлар” |
| 3) Г. Камал | В) “Әлдермештән Әлмәндәр” |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | |

**10. Авторны аның әсәре белән туры китерегез: (Һәрбер дөрес җавап өчен 1 б., иң югары – 4 б.)**

| **Автор** | **Әсәр** |
|---|---|
| 1) М.Әмир | А) “Алсу” |
| 2) Һ. Такташ | Б) “Миңлекамал” |
| 3) Г. Кутуй | В) “Мәрьям” |
| 4) Н.Исәнбәт | Г) “Тапшырылмаган хатлар” |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

### 3 бүлек. Рәсем белән эшләүгә нигезләнгән бирем.

**11. Фоторәсемне игътибар белән карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.**



**Фоторәсемдә кем сурәтләнгән? (1 б.)**

______________________________________________________________

**Аның тормыш юлы турында белгән мәгълүматларыгызны языгыз. (Һәрбер биографик факт өчен 1 б., иң югары – 5 б.)**

______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

### 4 бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр.

**12. Текстны игътибар белән укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез:**

*Без ачыгабыз, кулларыбызда балаларыбыз үлә, картлар үлә, яшьләр үлә, әмма без уңыш булган урыннардагы крестьян туганнар һәм шәһәр эшчеләре безне ярдәмнәреннән ташламаслар, ә Советлар бу ярдәмне оештырыр дип ышанабыз.*

*Без Европага, суыкта, ачлыкта булсак та, Октябрь казанышларын беркайчан да һәм беркемгә дә бирмәячәкбез дип белдерәбез.*

**Әлеге мөрәҗәгать хаты кем тарафыннан һәм кемгә атап язылган? (1б.)**

____________________________________________________________

**Әлеге документ кайчан язылган? (1 б.)**

____________________________________________________________

**13. Текстны игътибар белән укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез:**

*Иртәдән үк предприятиеләрдә митинглар үткәрелә башлады. Казан шартларында бу кадәр күп кеше катнашындагы мондый митинглар әлегә кадәр булмады, алар мондый гадәттән тыш күтәренкелек белән үткәрелмәде. Механика заводында митинг дүрт сәгать барды...*

*Митинглар шәһәрнең уку йортларында зур күтәренкелек белән үткәрелде. Университет коридорлары һәм заллары иртәннән үк матур киенгән һәм шат күңелле яшьләр белән тула башлады. Физкультура залында – музыка, анда студент егет һәм кызлар бии. Сәгать 10да шыгрым тулы залда митинг ачыла. Трибунада – университет җитәкчеләре. Анда катнашучылар һәлак булган геройларны баскан килеш тирән кайгы хисе белән искә алдылар, аннары Кызыл Армиягә "Ура" авазлары яңгырады...*

*Киров һәм Ленин районында массакүләм район митинглары үткәрелде, аларда 25 меңнән артык кеше катнашты. Әлеге митингларга предприятиеләр коллективлары оешкан төстә, байраклар, плакатлар, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре, Кызыл Армия командованиесе портретлары белән килделәр...*

**Чыганакта нинди митинг турында сүз бара? Ул нинди вакыйга белән бәйле? (1 б.)**

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

**Әлеге митинг кайчан үткәрелә? Аның төгәл көнен һәм елын билгеләгез. (1 б.)**

________________________________________________________________________________

**УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**